# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ “ГАИЛӘ” КОНЦЕПТЫ

*Хөснетдинов Д.Х.*

Туган тел һәр халыкның, һәрбер милләтнең тарихи үткәне, бүгенге яшәеше һәм киләчәк язмышы өчен гаять әһәмиятле факторларның берсе. Телдәге һәр күренешне өйрәнү, аның асылына төшенү халык туган теле тел һәм мәдәнияте арасындагы бәйләнеш дәрәҗәсен билгеләүдә дә мөһим роль уйный.

Телдә чагылыш тапкан лингвомәдәни үзенчәлекләрне, менталитетны ахырынача ачу – катлаулы гамәл. Бу мәсьәләне хәл итүне аларның асылын ачып бирә алучы төп концептларны билгеләүдән башка күз алдына да китереп булмый. Концепт структурасын тикшергәндә без милләтнең менталитетына, дөньяны танып белүенә һәм культурасына үтеп керәбез. Халыкның концептосферасын өйрәнү күп кенә сорауларга ачыклык кертергә, бер телдән икенче телгә тәрҗемә иткәндә дә хаталар җибәрмәскә булыша.

Бүгенге көндә төрки халыкларның милли культурасы концептуаль яссылыкта чагыштырмача аз өйрәнелгән. Татар лингвокультурологиясе һәм концептологиясе өлкәсендә Р.Р.Җамалетдинов, И.И.Мусина, Г.З.Шәрәева, Г.А.Садриева, Л.Р.Гарипова, Э.М.Зиангирова, Л.Х.Шәяхмәтова, Р.Р.Закирова, Ф.Х.Хәсәнова, Д.Х.Хөснетдинов һ.б. актив эшчәнлек алып баралар. Тикшеренүчеләр тарафыннан татар халкының материаль һәм рухи дөньясын концептлаштыру юнәлеше, татар дөнья тел күренешенең төп концептларын анализлау дәвам иттерелә, аерым өлкә яки сегментларга аерып күрсәтелә.

Гаиләнең бердәмлеге һәм аерымланып яшәве телдә аерым ачык итеп аңлатыла. Кан-кардәшлек бердәмлеге турыдан-туры пространстводагы бердәмлек белән тиңләштерелә. Төрле телләрдә йорт *гаилә, бергә яшәүче кешеләр* булып аңлатыла.

Бер йортта гаилә белән яшәү - гаиләне бердәй итүнең төп нигезе һәм төрки тел аңы вәкиле булган өйләнүче яшь егет өчен *үз йортыңны булдыру* иң элек җәмгыятьнең аерым гаиләсе булып китүне, үз өеңдә торуны белдерә,

сүзнең эчке формасы да (өйләнү) нәкъ шуңа ишарә ясый. Гаилә – кан-кардәшлек, никах бәйләнешләре; икътисади һәм хуҗалык мөнәсәбәтләре белән тупланган катлаулы тезелмә ул. Гаиләле булу татарларда электән хөрмәт ителгән, ә никахлашу зарури шарт кына түгел, ә мөселманнар өчен Аллаһ Тәгалә хакына башкарылучы изге гамәл дип кабул ителгән. Никахлашкан кеше ялгыз калган иң дини мөселманга караганда да Аллаһ тарафыннан күбрәк яклана, Аңа якынрак кешеләрдән санала.

*Гаилә* сүзе татар теленә гарәпчәдән килеп кергән. Беренче мәгънәсе - *өй җәмәгате, семья*. Телебездә ул, нигездә, нәкъ менә шушы мәгънәдә кулланыла. Гарәп телендә шулай ук *гаилә* сүзенең борчу, авыр эш, читен мәсьәлә дигән икенчел мәгънәсе дә урын ала. Ассоциатив яктан күпмедер дәрәҗәдә якынлык булса да, татар телендә әлеге мәгънәдә *гаилә* сүзе кулланылмый дип әйтергә дә урын бар [Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. 1993: 68].

Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә гаилә лексемасына түбәндәгечә аңлатма бирелә: *“Гаилә - бергә яшәүче ир, хатын, балалар һәм якын туганнардан торган кешеләр төркеме; семья.”* Мәсәлән, *Газиз үлү белән хөр һәм күңелле гаилә тормышы турындагы матур хыяллар берьюлы җимерелеп төште*.

Балалар тәрбияләү процессында гаиләнең иң мөһим вазифаларының берсе этномәдәният кыйммәтләрен тапшырудан, этник үзаң тәрбияләүдән гыйбарәт. Нәкъ менә гаиләдә балалар милли гореф-гадәт һәм йолалар белән, халык риваятьләре белән танышалар, шунда беренче дини күзаллаулары туа. Бер этнос вәкиле буларак формалашуда гаилә хәзер дә мөһим роль уйнавын дәвам итә.

Тикшеренүчеләр этномәдәният трансмиссиясендә гаилә әгъзалары арасында рольләр бүленешенең аерым үзенчәлекләре булуын билгеләп үтәләр. Аталар шул милләткә хас булган милли үзаң формалаштыруда күбрәк катнашалар, ә аналар исә нигездә мәдәният һәм көнкүреш эчтәлеге үзенчәлеген тапшыралар.

Татар гаиләсендә ана икътисади бәйле булып, иерархик буйсыну хәлендә яшәгән, ул гаиләдә йорт хуҗалыгын алып барырга, балаларны карап, тәрбияләп үстерегә тиеш булган, һәм бу яктан ул гаять мөһим эш башкарган.

Күчмә һәм күчемсез милекнең бердәнбер хуҗасы булган ир-ат һәм ата кеше татар җәмгыятендә гаилә тормышының төп мәсьәләләрен хәл итүдә өстенлекле хокукларга һәм гаиләдә кагылгысыз абруйга ия булган. Гаиләдә җитәкчелек һәм күзәтеп, тикшереп тору вазифасын нәкъ менә ир һәм ата башкарган.

Мәгълүм булганча, татар халкында иң хөрмәт ителгән нәрсәләрнең берсе – хезмәт. Традицион халык педагогикасында сабый чактан ук хезмәткә өйрәтү гаилә тәрбиясенең мөһим бурычы санала.

Татар гаиләсендә ата улларын тәрбияләү өчен, ә ана кызлары өчен җавап биргән.

Һәр халыкта туганлык бәйләнешләре, гаилә әгъзаларының нәсел-ыру, кардәшләр белән, шулай ук үзара да ни дәрәҗәдә якынлыкны, берсе икенчесенә кем булып чыгуын билгеләү мөһим урын алып тора. Бу исә, үз чиратында, арасында гаилә-туганлык бәйләнешләрен ачыклауга багышланган табышмаклар, төгәлрәк әйткәндә, *туганлыкны төпчеп белү* дигән аерым бер төр барлыкка килүгә этәргеч була. Әлеге төрдә гаилә концепты эчендә карала торган компонентлар комплекслы итеп (гаилә төшенчәсе составында) түгел, ә туганлык терминнарына (мәсәлән, ата, ана, әби, бабай һ.б.) аерым бүлеп карала. Гаиләнең һәр әгъзасы аерым билгеләп үтелә һәм табышмаклар шулай итеп төзелгән ки, аның җавабын эзләү барышында кешенең аңында үзара кан-кардәшлек, ныклы туганлык бәйләнешләре кат-кат ассызыклана.

“Гаилә” сүзе үз эченә күп төшенчәләрне берләштергән. Ул – без туып үскән әти-әни кочагы да булып тора. Кеше шәхес булып җитешеп гаиләдән читкә чыга һәм үз чиратында гаилә корырга тиеш була. Шуңа да гаилә һәркем өчен кадерле, мөһим, чөнки анда әти-әни, туганнар, һәм син шунда шәхес буларак формалашкан. Әдипләр дә “гаилә” төшенчәсен үз

иҗатларында бик теләп, яратып кулланалар һәм аңа төрле яклап якын киләләр, һәр сүзнең тәмен тоеп эш итәләр.

Әдәбият

Җамалетдинов Р.Р. Тел һәм мәдәният: Татар лингвокультурологиясе нигезләре. - Казан: Мәгариф, 2006.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 томда.- Т. 3 – Казан: 1981.

Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. 2 томда - Т 1. - Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – Б. 68.